ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 1618 «_07_»_____12___2016 ел

Өлкән буын гражданнар
мәнфәгатьләрендә эш итү
стратегиясен гамәлгә ашыру
чаралары планын раслау турында

Татарстан Республикасында Өлкән яшьтәге гражданнарны социаль яклау өлкәсендәге законнарны гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф. Х. Мөхәммәтшин белән очрашу беркетмәсенең 11 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. 2016-2018 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында өлкән буын гражданнар мәнфәгатьләрендә эш итү стратегиясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планын (кушымта) расларга. (килешү буенча).
2. Карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.П. Смирновага йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын

башкаручы И.М.Дәрҗеманов

Мамадыш муниципаль
районы Башкарма
комитетының
07.12.2016_№ 1618
карарына 1 нче кушымта

2016-2018 елларга Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында өлкән буын гражданнар мәнфәгатьләрендә эш итү стратегиясен гамәлгә ашыру буенча чаралар планы

| Пландагы чараның исеме | Үтәү вакыты | Җаваплы башкаручылар | Көтелгән нәтиҗә (индикатор) |
|---|---|---|---|
| 1. Сәламәтлек саклау өлкәсендә хезмәт күрсәтүләрдән тигез файдалануны тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар, 2. социаль яклау, мәгариф, туклану, мәдәният, спорт, элемтә, транспорт һ. б., шул исәптән авыл җирендә һәм ерак районнарда яшәүче өлкән буын гражданнары өчен | | | |
| Гражданнарны социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү тәртибе нигезендә консультатив хезмәтләр күрсәтеп, шул исәптән өйгә чыгып кабул итүне оештыру. | даими | Мамадыш муниципаль районының КЦСОН «Забота» | Социаль яклау өлкәсендәге хезмәтләрдән бертигез файдалануны саклау. |
| Өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның, шулай ук социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ затларның тиешле социаль ярдәм күрсәтү максатында яшәү шартларын тикшерү. | даими | Мамадыш муниципаль районының КЦСОН «Забота» | Социаль яклау өлкәсендәге хезмәтләрдән бертигез файдалануны саклау. |
| II. Мохтаҗ өлкән буын гражданнарының адреслы, үз вакытында ярдәм алуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар | | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Өлкән яшьтәге гражданнарның һәм социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ инвалидларның гомере һәм сәламәтлеге өчен куркыныч тудыручы ашыгыч хәлләрне хәл итүдә ярдәм күрсәтү буенча «мобиль бригада» чыгу. | даими | Мамадыш муниципаль районының КЦСОН «Забота» «Мобиль бригада», | Мохтаҗ өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга комплекслы социаль хезмәтләр күрсәтү. |
| III. Өлкән буын гражданнарының финанс хәлен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар | | | |
| Финанс куркынычсызлыгын һәм грамоталыкны тәэмин итү өчен хезмәт күрсәтүче гражданнар арасында аңлату эшләре алып бару. | даими | Мамадыш муниципаль районының КЦСОН «Забота» | Өлкән яшьтәге гражданнарны финанс хезмәтләре кулланучылар буларак яклау. |
| IV. Хәзерге икътисад шартларында өлкән буын гражданнарының финанс һәм хокукый белеме дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән гамәлләр | | | |
| Халыкка, өйдә хезмәт күрсәтүдә торучы гражданнарга консультатив, социаль-хокукый хезмәт күрсәтү | даими | социаль яклау бүлеге, нотариаль , адвокат конторалары, Мамадыш муниципаль районының КЦСОН «Забота» | Өлкән яшьтәге гражданнарның хокукый грамоталыгын һәм социаль-хокукый яклanганын тәэмин итү. |
| Өлкәннәр өчен бушлай юридик ярдәм көнен оештыру | 2016-2018 еллар октябре график буенча | социаль яклау бүлеге, нотариаль , адвокат конторалары, | Өлкән яшьтәге гражданнарның хокукый грамоталыгын һәм социаль-хокукый якланганын тәэмин итү. |
| V Өлкән буын гражданнарына мәгълүматтан файдалана алуны тәэмин итү өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чаралар | | | |
| «Компьютер әлифбасы» | Кирәк булганда | Мамадыш муниципаль районының КЦСОН «Забота» | өлкән яшьтәге кешеләр интернет аша файдалы мәгълүмат алачак;<br>Үсеп килүче буын белән бертигез |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | дәрәҗәдә хис итәрләр;<br><br>башка шәһәрләрдә булган туганнары һәм дуслары белән аралаша алачак. |
| VI. Өлкән буын гражданнарының физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүе өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чаралар | | | |
| «Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау» социаль хезмәтләр алучылар белән сәламәтләндерү чараларын үткәрү һәм «Сәламәтлек» клубының социаль-тернәкләндерү бүлегендә эшләве. | Атна саен | Мамадыш муниципаль районының КЦСОН «Забота» Мамадыш районы үзәк хастаханәсе | Сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау буенча актив төркемнәр булдыру;<br><br>- Зарарлы гадәтләрнең төрләре, аларның барлыкка килү сәбәпләре, зарарлы бәйлелекләрне көрәш һәм профилактикалау чаралары, кеше организмы өчен заманча аспекттагы нәтиҗәләр турында теоретик белемнәрне тирәнәйтү, шулай ук организмга теге яки бу зарарлы гадәтнең тәэсире дәрәҗәсен бәяләүнең гамәли күнекмәләрен алу;<br><br>- Авыруларның кимүе. |

VI. Өлкән буын гражданнарының физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүе өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чаралар

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Олимп» спорт савыктыру комплексында бассейнга ташламалы йөрүне оештыру | 2016-2018 елларга аерым расписание буенча | «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге»МКУ | Өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау |
| Өлкән яшьтәге гражданнарга чаңгы биреп, чаңгы трассасы эшен оештыру | 2016-2018 елларга аерым расписание буенча | «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге»МКУ | Өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау |
| Шахмат клубы эшен оештыру һәм өлкән яшьтәге гражданнар арасында шахмат турнирлары үткәрү | 2016-2018 | «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге»МКУ | Өлкән яшьтәге гражданнарның тормыш сыйфатын күтәрү, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау |
| «Скандинавия йөреше» программасы буенча «Кайгырту»халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекчәсенең өлкән яшьтәге гражданнары белән савыктыру чаралары үткәрү | 2016-2018 | Мамадыш муниципаль районының КЦСОН «Забота» », «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге»МКУ | Өлкән яшьтәге гражданнарның һәм инвалидларның тормыш сыйфатын күтәрү, картлыкның актив фазасын арттыру, физик һәм психик сәламәтлекне саклау |
| Өлкән буын гражданнарын (ата-аналарны, Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветераннарын) чакырып, сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлдерелгән чаралар үткәрү.<br>Спорт ветераннарын чакырган класс сәгатьләре.<br>Бөтен гаилә өчен спорт бәйрәмнәре | Әлеге чор дәвамында | Башкарма комитетның «Мәгариф бүлеге» МКУ, ветераннар Советы | Сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыру Охшарга тырышу үрнәге буларак өлкән буын гражданнарының тормышына стимулны арттыру<br>Гаилә кыйммәтләрен һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау |
| VII. Өлкән буын гражданнарын җәмгыятьнең мәдәни тормышына җәлеп итүгә юнәлдерелгән чаралар | | | |
| Бөек Ватан сугышында Җиңү | 2016-2018 елларның | Мамадыш муниципаль | Өлкән буын гражданнарын |

| | | | |
|---|---|---|---|
| көненә багышланган Батырлык дәресләре. | Февраль, Май айлары | районының КЦСОН «Забота» , Ветераннар советы | җәмгыятьнең мәдәни тормышына җәлеп итү. |
| Өлкәннәр көненә багышланган чаралар.. | Октябрь 2016 -2018 еллар | Районның авыл җирлекләре Башкарма комитетлары, Мамадыш муниципаль районының КЦСОН «Забота» | Өлкән буын гражданнарын җәмгыятьнең мәдәни тормышына җәлеп итү |
| Бөек Ватан сугышында Җиңү көненә багышланган чаралар уздыру | 2 квартал 2016-2018 еллар | Районның авыл җирлекләре Башкарма комитетлары, Мамадыш муниципаль районының КЦСОН «Забота» | Өлкән буын гражданнарын җәмгыятьнең мәдәни тормышына җәлеп итү |
| Инвалидлар декадасына багышланган чараларны оештыру һәм үткәрү. | Декабрь 2016-2018 еллар | Мамадыш муниципаль районының КЦСОН «Забота» | Өлкән буын гражданнарын җәмгыятьнең мәдәни тормышына җәлеп итү |
| Өлкән яшьтәге гражданнар арасында «Балкыш» фестивален оештыру. | Ел саен 2016-2018еллар | Ветераннар советы,”Мәдәният бүлеге " МКУ | Өлкән буын гражданнарын җәмгыятьнең мәдәни тормышына җәлеп итү |
| Мамадыш картлар һәм инвалидлар интернат-йорты "ДАСУ дә тәрбияләнүчеләр өчен чаралар | Әлеге чор дәвамында | «Мамадыш картлар һәм инвалидлар интернат-йорты "ДАСУ,»мәдәният бүлеге" МКУ | |
| Инвалидлар һәм ветераннарга музейларга бушка керүне оештыру | 2016-2018 еллар | Социаль яклау бүлеге, «Мәдәният бүлеге» МКУ | Халык традицияләрен һәм халык иҗатын популярлаштыру Өлкән буын кешеләрен үзешчән сәнгатьнең төрле төрләренә җәлеп итү. |
| Проведение районного этапа | Ел саен | Башкарма комитет, | Өлкән буын гражданнарын |

| | | | |
|---|---|---|---|
| республиканского конкурса «Женщина года. Мужчина года:женский взгляд» с участием кандидата в номинации «Героиня третьего возраста» | | ветераннар советы, социаль яклау бүлеге | җәмгыятьнең мәдәни тормышына җәлеп итү |
| VIII. Өлкән буын гражданнары өчен туристлык хезмәтләреннән файдалану мөмкинлеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар | | | |
| Социаль туризм | Ел дәвамында | Мамадыш муниципаль районының КЦСОН «Забота», «Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге» МКУ | Тормышка кызыксынуны арттыру;<br>Аралашу даирәсен киңәйтү;<br>Сәламәтлекне ныгыту;<br>Пенсионерларның һәм инвалидларның тормыш активлыгын арттыру, эмоциональ тормышларын баету;<br>Дөрес һәм файдалы ялны оештыру;<br>Өлкән яштәге кешеләрнең тормыш тонусын, кәефен күтәрү. |
| "Социаль туризм" программасын гамәлгә ашыру:<br>- Болгарга, Зөягә экскурсияләр,<br>-Казанга, Кол Шәриф мәчетенә экскурсияләр,<br>- Раифский монастырена экскурсияләр һ. б. | 2016-2018 | Башкарма комитет, ветераннар советы, КЦСОН «Забота» | Тормышка кызыксынуны арттыру, аралашу даирәсен киңәйтү, сәламәтлекне ныгыту, тормыш активлыгын арттыру |
| IX. Өлкән буын гражданнарның сәламәтлеген саклау системасын камилләштерүгә юнәлдерелгән чаралар;<br>гериатрия хезмәтен һәм тәрбияләүгә ихтыяҗны бәяләү системасын үстерү | | | |
| Авыл җирендә яшәүче өлкән яштәге | 2016-2018 еллар | Авыл җирлекләре | Өйдә хезмәт күрсәтелүче өлкән яштәге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| гражданнар ихтыяҗларына туры килә торган социаль хезмәт күрсәтүләрне гамәлгә кертү | | башкарма комитетлары, Мамадыш муниципаль районының КЦСОН «Забота» | гражданнар саны арту. |
| Мамадыш муниципаль районы территориясендә " өлкән кешене тәрбиягә алучы гаилә» пилот проектын гамәлгә ашыру, «Өлкән кешене тәрбиягә алучы гаилә»стационарны алмаштыра торган технологияне кертү | 2016 -2017 | Мамадыш муниципаль районында социаль яклау бүлеге, опека һәм попечительлек бүлеге | Өй шартларында яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар санын арттыру |
| X. Күпформатлы сәүдә инфраструктурасын үстерү аша өлкән буын гражданнары һәм эшкуарлык эшчәнлеге субъектлары өчен уңайлы куллану мохите булдыру өчен шартлар тудыруга; сәүдә инфраструктурасын тотрыклы үстерүгә юнәлдерелгән чаралар | | | |
| Азык-төлек товарларын түбән бәяләрдән сату буенча авыл хуҗалыгы ярминкәләре үткәрү | 2016-2018 | Районның һәм авыл җирлекләре башкарма комитетлары, районның авыл хуҗалыгы идарәсе | Өлкән яшьтәге гражданнарның гомер сыйфатын һәм озынлыгын яхшырту |
| XI. Өлкән буын гражданнар мәнфәгатьләрендә хәйрия эшчәнлеген һәм ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген үстерүгә юнәлдерелгән чаралар | | | |
| Өйдәге бүлекләрдә социаль хезмәт күрсәтүдәге ялгыз һәм ялгыз яшәүче гражданнарга өйдә өстәмә социаль хезмәт күрсәтү өчен шәһәр мәктәпләре укучылары арасыннан волонтерлар җәлеп итү. | даими | Мамадыш муниципаль районының КЦСОН «Забота» , МКУ «Отдел образования» | Өлкән буын гражданнар мәнфәгатьләрендә ирекле (волонтерлык) эшчәнлеген үстерү. |
| XIIӨлкән буын кешеләренә карата уңай һәм ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыруга, барлык халыкның демографик үзгәрешләргә әзерлеген арттыруга юнәлдерелгән чаралар | | | |
| Студентлар өчен өйдә социаль | Кирәк булганда | Мамадыш муниципаль | Өлкән буын кешеләренә уңай |

| | | | |
|---|---|---|---|
| хезмәт күрсәтү бүлекләрендә практика узуны оештыру | | районының КЦСОН «Забота» директоры урынбасары | һәм ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру. |
| Мәктәп укучыларын һәм имин булмаган гаиләләрдәге балаларны патриотик тәрбияләүгә юнәлдерелгән чаралар оештыру һәм үткәрү | 2016-2018 | МКУ Мәгариф бүлеге яшьләр эшләре, спорт бүлеге | Өлкән буын кешеләренә уңай һәм ихтирамлы мөнәсәбәт формалаштыру |
| XIII. Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре тәкъдим итә торган өстәмә чаралар | | | |
| «Чиста йорт " акциясен үткәрү | Апрель-май | Мамадыш муниципаль районының КЦСОН «Забота» » | «Кайгырту»халыкка социаль хезмәт күрсәтү үзәгенең өлкән яшьтәге гражданнары өчен ел саен үткәрелә торган «Чиста йорт» акциясен үткәрү |
| Ир белән хатынны, никах юбилярларын, Бөек Ватан сугышы ветераннарын котлау | Ел дәвамында | ЗАГС бүлеге, Ветераннар Советы, районның авыл җирлекләре | Авыр сугыш елларын кичергән ир белән хатынны хөрмәтләү |

Җитәкче урынбасары А.П. Смирнова